РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.10.2022 ел Буа шәһәре № 301/Бк-к

Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия
Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби
хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы гражданнары
гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы (24.09.2022ел редакциясендә), «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» (30.12.2021ел редакциясендә) Федераль законнарга, «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

1.1. Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә өстәмә белем бирү түгәрәкләрендә һәм секцияләрендә дәресләр өчен түләүдән азат итәргә;

1.2. Буа туган якны өйрәнү музеена, шулай ук Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан спорт комплексларына бушлай керүне (йөрүне) оештырырга.

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул итүнең беренче чираттагы хокукын тәэмин итәргә.

3.Тәкъдим итәргә:

3.1. «Буа шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә

- эш эзләү буенча теркәлүчегә эш эзләүдә;
- һөнәри әзерлекне оештыруда һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алуда ярдәм итәргә;

3.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә гаиләсе алырга хокуклы социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерүдә булышлык күрсәтергә;

3.3. «Буа ветеринария техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә, «Буа медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә I, II төркем инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар арасыннан гаилә әгъзаларына фатир, йорт яны кишәрлеген җыештыру буенча волонтерлык ярдәме күрсәтергә (кышкы чорда).

4. Буа муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләргә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хезмәткәрләргә бер тапкыр түләнә торган түләүләр рәвешендә өстәмә социаль гарантияләр билгеләргә, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәмнең өстәмә чараларын карарга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылырга тиеш: http//buinsk.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов